ГЛАВА СТАРОКАРАЗЕРИКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Старый Каразерик, ул.Советская, д.12, 423965

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ КАРАЗИРЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Иске Каразирек авылы, Совет урамы, 12 йорт, 423965

Тел.:(85593) 4-12-27, факс:4-12-27, e-mail: Skar.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИE** **КАРАР**
**№1** **07.11.2025**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлеге составына керүче Яңа Каразирек торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14 маддәсе нигезендә, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында»гы нигезләмәгә таянып,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2025 елның 18 ноябрендә 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Яңа Каразирек авылы, Пионерлар урамы, 18 йорт адресы буенча урнашкан Яңа Каразирек торак пунктындагы авыл клубы бинасында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлегенең Яңа Каразирек торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«2026 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлеге Яңа Каразирек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан, сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучыларның якын туганнары (ата-аналары, балалары), Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Яңа Каразирек торак пунктының Комсомол урамындагы юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (асфальт салу, ремонтлау, вак таш салу, ПГС салу, ташу, төзелеш материаллары сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү)

- Яңа Каразерик торак пунктында традицион күмү урыннарын төзекләндерү, коймалап алу, ремнотлау (зират территориясен ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, эш өчен килешү буенча түләү);

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлеге башкарма комитетына Яңа Каразирек торак пунктында гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://jutaza.tatarstan.ru.), Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru / электрон адресы буенча кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Иске Каразирек авыл җирлеге башлыгы И.Р.Гәрәев